**2024-2025 уку елы**
**Интернет тур.**

**8-9 нчы сыйныфлар**
**1 нче вариант**
**А тибындагы биремнәр барысы да 4 балл белән, В тибындагы биремнәр барысы да 6 балл белән бәяләнә.**

1. **Алынма сүзне табыгыз. (4 балл).**
1) Кашык
2) Кырык
3) **Кәгазь**
4) Кыргыч

2. **Үткән заман сыйфат фигыль кулланылган җөмләне табыгыз. (4 балл).**
1) **Килгән кунаклар озак тормадылар.**
2) Үткән заман сыйфат фигыль кулланылган җөмләне табыгыз.
3) Яңа дәрестә булачак күнегүләргә әзерләндек.
4) Дустым әлеге китапны кичә үк укыган икән.

3. **Фразеологизмның мәгънәсен табыгыз. (4 балл).** *Түбәсе күккә тигән –*
1) **Куанган**
2) Сикергән
3) Борчылган
4) Авырган

4. **Фигыль сүзтезмәне табыгыз. (4 балл).**
1) Кычкырган тавыш
2) Әйтәсе сүз
3) Тырыш бала
4) **Борчылмаска тырышу**

5. **Орфографик хатасы булган сүзне табыгыз. (4 балл).**
1) **Сәләмләү**
2) Бәяләү
3) Хыяллану

4) Һәвәсләнү

6. **Сөенү сүзенең синонимын табыгыз. (4 балл).**

1) Көенү
2) Кайгыру
3) **Шатлану**
4) Көлү

7. **Дүрт мәгънәле кисәктән торган сүзне табыгыз. (4 балл).**

1) Карсызлык
2) Әбиләрдән
3) **Сабакташларым**
4) Онытылды

8. **Тартыклары саңгырау гына булган сүзне табыгыз. (4 балл).**

1) Кәҗә
2) Сарык
3) Бозау
4) **Поши**

9. **Җөмләдә төшеп калган  тыныш билгесен табыгыз. (4 балл).**
*Поездан төшкәч  10 минут җәяү барырга туры киләчәк.*

1. өстәмә тыныш билгесе куелмый
2. сызык
3. **өтер**
4. ике нокта

10. **Синтетик иярченле кушма җөмлә белән белдерелгән мәкальне табыгыз. (4 балл).**

1) Алтынны тоткан кеше генә таный.
2) Алтын кулны пычак кисмәс.
3) **Алтыны барда җүләрне дә акыллы диләр.**
4) Алтын чүплектә дә ялтырый.

11. **Сүзләр һәм аларның тәрҗемәләрен тәңгәллек белән күрсәтегез. Җавапны хәрефләр тезмәсе белән тыныш билгеләрсез һәм буш ара калдырмыйча языгыз. (6 балл).**

| СҮЗ | ТӘРҖЕМӘСЕ |
| --- | --- |
| 1) чувство | А) хокук |
| 2) служба | Ә) хис |
| 3) право | Б) хөрмәт |
| 4) уважение | В) хезмәт |

**Җавап (Ответ): ӘВАБ**

12. **Сүзләр һәм аларның синонимнарын тәңгәлләштерегез. Җавапны хәрефләр тезмәсе белән тыныш билгеләрсез һәм буш ара калдырмыйча языгыз. (6 балл).**

| СҮЗ | СИНОНИМЫ |
|---|---|
| 1) ябык | А) каплану |
| 2) яклау | Ә) чандыр |
| 3) ябыну | Б) тараф |
| 4) як | В) саклау |

Җавап: ӘВАБ

13. **Төшеп калган сүзне языгыз (6 балл).**

*Алар дусларча сөйләшеп утырдылар (Ш.М.)* җөмләсендәге *дусларча* сүзе <...> сүз төркеменә карый.

**Җавап (Ответ): РӘВЕШ**

***14 Ягъни*** **сүзендәге я хәрефе кайсы авазларны белдерә? (6 балл).**

**Җавап (Ответ): ЙӘ**

15. **МӘНФӘГ...ТЬ сүзендә кайсы хәреф төшеп калган? Төшеп калган хәрефне языгыз. (6 балл).**

**Җавап (Ответ): А**

**16. Тексттан хәл фигыльләр кулланылган җөмләләрне табыгыз һәм аларның санын арта бару тәртибендә күрсәтегез. (6 балл).**

1) Беркөнне савыттан сөт эчкән вакытта, песиләр кечкенә генә бер көчекне күргәннәр. 2) Ул кап-кара төстә булган. 3) Бу көчекнең дә сөт эчеп карыйсы килгән. 4) Ул, койрыгын болгый-болгый, песиләргә карап тора икән.

5) Ак песигә көчек ошамаган. 6) Ул аңа ачуланып:

- 7) Кит моннан!- дигән.

8) Соры песи Ак песигә аптырап караган.

-9) Ни өчен, Аппагым? 10) Күрәсеңме, безнең кунагыбызның да сөт эчәсе килгән бит! – дигән.

*Резеда Вәлиева*

**Җавап (Ответ): 3468**

**17. Төшеп калган терминны языгыз. (6 балл).**

**Тел гыйлеменең җирле сөйләшләрне өйрәнә торган тармагы** <...> **дип атала.**

**Җавап (Ответ): ДИАЛЕКТОЛОГИЯ**

18. **Фигыльләрне төркемчәләре буенча тәңгәлләштерегез. Җавапны тыныш билгеләрсез, буш ара калдырмыйча саннар тезмәсе белән языгыз. (6 балл).**

| | |
|---|---|
| А) адашкан яз | 1) исем фигыль |
| Ә) ашыктыргач | 2) хәл фигыль |
| Б) зиһен таралу | 3) хикәя фигыль |
| В) карамаган иде | 4) сыйфат фигыль |

**ОТВЕТ: 4213**

19. **Фразеологизмнар һәм аларның мәгънәләре арасында тәңгәллек урнаштырыгыз. Җавапны тыныш билгеләрсез, буш ара калдырмыйча саннар тезмәсе белән языгыз. (6 балл).**

| | |
|---|---|
| А) тәлинкә тоту | 1) борчылу |
| Ә) кәкре каенга terәтү | 2) ялагайлану |
| Б) ут йоту | 3) үпкәләү |
| В) сүз күтәрмәү | 4) алдау |

**ОТВЕТ: 2413**

**20. Текстта артыклык дәрәҗәсендә килгән сыйфат булган җөмләнең номерын языгыз. (6 балл).**

1) Беркөнне савыттан сөт эчкән вакытта, песиләр кечкенә генә бер көчекне күргәннәр. 2) Ул кап-кара төстә булган. 3) Бу көчекнең дә сөт эчеп карыйсы килгән. 4) Ул, койрыгын болгый-болгый, песиләргә карап тора икән.

5) Ак песигә көчек ошамаган. 6) Ул аңа ачуланып:

- 7) Кит моннан!- дигән.

8) Соры песи Ак песигә аптырап караган.

-9) Ни өчен, Аппагым? 10) Күрәсеңме, безнең кунагыбызның да сөт эчәсе килгән бит! – дигән.

*Резеда Вәлиева*

**Җавап (Ответ): 2**

**2 нче вариант**

**А тибындагы биремнәр барысы да 4 балл белән, В тибындагы биремнәр барысы да 6 балл белән бәяләнә.**

1. **Алынма сүзне табыгыз. (4 балл.)**

1) Ашамлык
2) Эчемлек
**3) Ризык**
4) Икмәк

2. **Үткән заман сыйфат фигыль кулланылган җөмләне табыгыз. (4 балл.)**
   **1) Укыган китабым бик кызык иде: аерыла алмадым.**
   2) Төп фикер әйтелә торган җөмләне табыгыз.
   3) Яңа дусларымның барасы җире бар иде.
   4) Синең фикер мине бик кызыксындырды.

3. **Фразеологизмның мәгънәсен табыгыз. (4 балл.)**

Борыны салынган –

1) Борчылган
**2) Кәефе төшкән**
3) Томау төшкән
4) Елаган

4. **Фигыль сүзтезмәне табыгыз. (4 балл.)**

**1) Учак ягу**
2) Сүнгән учак
3) Матур кич
4) Уйчан караш

5. **Орфографик хатасы булган сүзне табыгыз. (4 балл.)**

1) Шакылдау
2) Пышылдау
**3) Тәңкыйтьләү**
4) Тәрбияләү

6. ***Һичкем* сүзенең синонимын табыгыз. (6 балл).**

1) Барысы
2) **Беркем**
3) Һәммәсе
4) Әллә кем

7. **Дүрт мәгънәле кисәктән торган сүзне табыгыз. (4 балл.)**

   1) Болавык
   2) балыкчы
   3) **хезмәттәшләрем**
   4) җылылык

8. **Тартыклары саңгырау гына булган сүзне табыгыз. (4 балл.)**

   1) **Сатучы**
   2) Кибетче
   3) Балыкчы
   4) Төзүче

9. **Җөмләдә төшеп калган тыныш билгесен табыгыз. (4 балл.)**

*Мин шуны аңлыйм бүген алар мине үгетлиячәкләр.*

   1) өстәмә тыныш билгесе куелмый
   2) сызык
   3) өтер
   4) **ике нокта**

10. **Синтетик иярченле кушма җөмлә белән белдерелгән мәкальне табыгыз. (4 балл.)**

   1) Күп дус эзләгән дуссыз калыр.
   2) Ялганчы ялчымас, угры баемас.
   3) **Эше күпнең көче күп.**
   4) Матур эшләсәң, матур ашарсың.

11. **Сүзләр һәм аларның тәрҗемәләрен тәңгәллек белән күрсәтегез. Җавапны хәрефләр тезмәсе белән тыныш билгеләрсез һәм буш ара калдырмыйча языгыз. (6 балл).**

| СҮЗ | ТӘРҖЕМӘСЕ |
|---|---|
| 1) очередь | А) борчылу |
| 2) смежный | Ә) чират |
| 3) беспокойство | Б) чишелеш |
| 4) развязка | В) чиктәш |

**Җавап (Ответ): ӘВАБ**

12. **Сүзләр һәм аларның синонимнарын тәңгәлләштерегез. Җавапны хәрефләр тезмәсе белән тыныш билгеләрсез һәм буш ара калдырмыйча языгыз. (6 балл).**

| СҮЗ | СИНОНИМЫ |
|---|---|
| 1) басым | А) тоя |
| 2) яклый | Ә) йогынты |
| 3) сизә | Б) абруй |
| 4) дәрәҗә | В) хуплый |

Җавап: ӘВАБ

13. **Төшеп калган сүзне языгыз. (6 балл).**

*Шыгырдап торган ак карны җил тиз-тиз очырта башлады (Ш.М.)* җөмләсендәге *тиз-тиз* сүзе <...> сүз төркеменә карый.

**Җавап (Ответ): РӘВЕШ**

14. ***Ярар* сүзендәге я хәрефе кайсы авазларны белдерә? (6 балл).**

**Җавап (Ответ): ЙА**

15. **ИТАГ...ТЬ сүзендә кайсы хәреф төшеп калган? Төшеп калган хәрефне языгыз. (6 балл).**

Җавап (Ответ): А

**16. Тексттан зат алмашлыклары кулланылган җөмләләрне табыгыз һәм аларның санын арта бару тәртибендә күрсәтегез (6 балл).**

1. Беркөнне Фәрит әнисенең кушуы буенча кибеткә барган иде. 2) Каракай да аңа иярде. 3) Шунда прилавка янында әйберләр караган чакта, бер хатын кинәт:

–4) Урладылар, акчамны урладылар!-дип кычкырып җибәрде.

5) Фәрит, аны-моны уйлап тормыйча, әлеге хатынга:

- 6) Тизрәк кульяулыгыгызны чыгарыгыз! – диде.

7) Хатын да: “Нигә?” – дип сорамады, сумкасыннан бизәкле кульяулыгын алып, Фәриткә бирде.

8) Фәрит аны тиз генә Каракай борынына китереп иснәтте дә:

-9) Тиз эзлә! – диде.

10) Каракай сискәнеп киткән кебек булды, әйтерсең, ул кинәт йокысыннан уянып китте. 11) Арт аякларына басып, башын як-якка боргалый-боргалый иснәде дә кинәт чабып китте.

*Нәби Дәүли*

**Җавап (Ответ): 2810**

17. **Төшеп калган терминны языгыз. (6 балл).**
**Тел гыйлеменең тотрыклы сүзтезмәләрне өйрәнә торган тармагы** <...> **дип атала.**

**Җавап (Ответ): ФРАЗЕОЛОГИЯ**

18. **Фигыльләрне төркемчәләре буенча тәңгәлләштерегез. Җавапны тыныш билгеләрсез, буш ара калдырмыйча саннар тезмәсе белән языгыз. (6 балл).**

| | |
|---|---|
| А) сайрар сандугач | 1) исем фигыль |
| Ә) кызыксындырганчы | 2) хәл фигыль |
| Б) башны катыру | 3) хикәя фигыль |
| В) уйламаганиде | 4) сыйфат фигыль |

**ОТВЕТ: 4213**

19. **Фразеологизмнар һәм аларның мәгънәләре арасында тәңгәллек урнаштырыгыз. Җавапны тыныш билгеләрсез, буш ара калдырмыйча саннар тезмәсе белән языгыз.**

| | |
|---|---|
| А) күз салу | 1) ачулану |
| Ә) ут йоту | 2) карау |
| Б) тетмәсен тетү | 3) курку |
| В) кот чыгу | 4) борчылу |

**ОТВЕТ: 2413**

**20. Текстта чагыштыру дәрәҗәсендә килгән рәвеш булган җөмләнең номерын языгыз.**

1. Беркөнне Фәрит әнисенең кушуы буенча кибеткә барган иде. 2) Каракай да аңа иярде. 3) Шунда прилавка янында әйберләр караган чакта, бер хатын кинәт:

–4) Урладылар, акчамны урладылар!-дип кычкырып җибәрде.

5) Фәрит, аны-моны уйлап тормыйча, әлеге хатынга:

- 6) Тизрәк кулъяулыгыгызны чыгарыгыз! – диде.

7) Хатын да: “Нигә?” – дип сорамады, сумкасыннан бизәкле кулъяулыгын алып, Фәриткә бирде.

8) Фәрит аны тиз генә Каракай борынына китереп иснәтте дә:

-9) Тиз эзлә! – диде.

10) Каракай сискәнеп киткән кебек булды, әйтерсең, ул кинәт йокысыннан уянып китте. 11) Арт аякларына басып, башын як-якка боргалый-боргалый иснәде дә кинәт чабып китте.

*Нәби Дәүли*

**Җавап (Ответ): 6**